КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 июнь г.Казань № 679

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче; 2020 ел, 24 июль, 621 нче; 2020 ел, 26 октябрь, 956 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1229 нчы; 2021 ел, 21 май, 353 нче; 2021 ел, 19 июль, 586 нчы; 2021 ел, 6 ноябрь, 1055 нче; 2022 ел, 27 гыйнвар, 62 нче;

2022 ел, 15 март, 238 нче; 2022 ел, 22 март, 254 нче; 2022 ел, 16 май, 444 нче; 2022 ел, 23 август, 886 нчы; 2022 ел, 12 сентябрь, 985 нче; 2022 ел, 17 декабрь, 1360 нчы; 2023 ел, 6 февраль, 108 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="15">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td><td colspan="3">Программаны финанслауның гомуми күләме 27 391 539,35 мең сум тәшкил итә*, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырылган федераль бюджет акчасы – 18 229 242,5 мең сум*, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 162 296,85 мең сум*.<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>957 036,6</td><td>668 907,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>771 639,0</td><td>631 712,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>742 042,5</td><td>683 366,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>609 879,1</td><td>721 262,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>575 168,1</td><td>755 325,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 124 229,6</td><td>766 880,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>4 587 147,4</td><td>774 413,2</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 479 897,0</td><td>786 024,9</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 675 244,1</td><td>745 867,07</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2 620 291,7</td><td>855 698,3</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1 526 727,7</td><td>878 250,9</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>1 559 939,7</td><td>894 587,8</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>18 229 242,5</td><td>9 162 296,85»;</td></tr>
</table>

Программаның III бүлегендә:

икенче абзацта «27 426 177,85» саннарын «27 391 539,35» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «18 264 279,1» саннарын «18 229 242,5» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «9 161 898,75» саннарын «9 162 296,85» саннарына алмаштырырга;

Программага 2 нче кушымтада:

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь

инвалидларга булышлык күрсәтеп тору» юлының 12 графасында:

«барлыгы» өстәмә юлында «3 495 998,5» саннарын «3 461 360,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» өстәмә юлында «840 670,2» саннарын «841 068,3» саннарына алмаштырырга;

«федераль бюджет (җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча)» өстәмә юлында «2 655 328,3» саннарын «2 620 291,7» саннарына алмаштырырга;

«Программа буенча барысы, шул исәптән:» юлында «3 510 628,5» саннарын «3 475 990,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлында «855 300,2» саннарын «855 698,3» саннарына алмаштырырга;

«федераль бюджет (җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча)» юлында «2 655 328,3» саннарын «2 620 291,7» саннарына алмаштырырга;

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасында (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы):

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="12">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 27 245 696,65 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 18 229 242,5 мең сум*, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 016 454,15 мең сум*, шулардан инвалидларны (яшь инвалидларны кертеп) эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтүгә һәм эш белән тәэмин итүгә даими булышлык күрсәтеп торуга – 300,2 млн.сум.<br><br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">Акчаның гомуми күләме</td><td colspan="2">Шул исәптән</td></tr>
<tr><td>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>1 611 314,39</td><td>957 036,6</td><td>654 277,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 388 721,01</td><td>771 639,0</td><td>617 082,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 410 779,48</td><td>742 042,5</td><td>668 736,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 315 776,8</td><td>609 879,1</td><td>705 897,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>1 315 863,1</td><td>575 168,1</td><td>740 695,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 876 479,8</td><td>1 124 229,6</td><td>752 250,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>5 356 930,6</td><td>4 587 147,4</td><td>769 783,2</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2 261 492,7</td><td>1 479 897,0</td><td>781 595,7</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2022 | 2 416 732,67 | 1 675 244,1 | 741 488,57 |
| | 2023 | 3 461 360,0 | 2 620 291,7 | 841 068,3 |
| | 2024 | 2 390 348,6 | 1 526 727,7 | 863 620,9 |
| | 2025 | 2 439 897,5 | 1 559 939,7 | 879 957,8 |
| | Бар-лыгы | 27 245 696,65 | 18 229 242,5 | 9 016 454,15»; |

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының I бүлегендәге «Хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 2309 номерлы карары нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасында «Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре хезмәткәрләрен, шулай ук яраклы эш эзләүдә ярдәм сорап халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән һәм оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре белән укыту шартнамәсе төзегән гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү» чарасын гамәлгә ашыру турында карар кабул ителде.»;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының II бүлегендә:

егерме алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;»;

егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен, шулай ук яраклы эш эзләүдә ярдәм сорап халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән һәм оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре белән укыту шартнамәсе төзегән гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү;»;

егерме тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү (башка җирлектә укуны кертеп) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру,Татарстан Республикасында яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында яраклы эш эзләү максаты белән теркәлгән гражданнарны, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән эшсез гражданнарны һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башларга теләгән эшсез пенсионерларның башка категорияләрен һәм Россия Федерациясе Президентының «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү дәүләт фондын төзү турында» 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән затларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;»;

утыз беренче абзацта «дәүләт хезмәте» сүзләрен «дәүләт хезмәтләре» сүзләренә алмаштырырга;

илле дүртенче абзацта «икътисадый актив халыкны» сүзләрен «эш көчен» сүзләренә алмаштырырга;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының III бүлегендә:

беренче абзацта «27 280 335,15» саннарын «27 245 696,65» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «18 264 279,1» саннарын «18 229 242,5» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «9 016 056,05» саннарын «9 016 454,15» саннарына алмаштырырга;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының 2 нче кушымтасындагы «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасында:

1.9 пунктның 17 графасында «490 336,8» саннарын «490 734,9» саннарына алмаштырырга;

2.1 пунктның 17 графасында «4 141,2» саннарын «4 495,13» саннарына алмаштырырга;

2.4.3 пунктчаның 9 графасында «кимендә 55» сүзләрен «0» санына алмаштырырга;

2.4.3.1 пунктчада:

3 графада «2022 ел» сүзләрен «2022 – 2023 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

9 графага «кимендә 55» сүзләрен өстәргә;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.6. Эшсез гражданнарга, шул исәптән пенсия алды яшендәге гражданнарга, шулай ук РФ Хөкүмәтенең 376 номерлы карарында күрсәтелгән гражданнарга эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауда булышлык күрсәтү (гражданнарга оештыру- | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТ И ДУ | 2022 – 2023 еллар | хисап чорында теркәлгән эшсез гражданнарның, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 376 номерлы карарында күрсәтелгән гражданнарның гомуми санында үз эшен башлап җибәргән гражданнар өлеше, процент | | | | кимендә 0,6 | кимендә 0,6 | | | ТР бюджеты | | | | 63 103,6 | 63 662,0»; | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тыру-консультация ярдәме күрсәтүне, индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп), шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

3.6.1 пунктчаның 17 графасына «543,5» саннарын өстәргә;
3.6.2 пунктчаның 17 графасына «63 118,5» саннарын өстәргә;
3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.7. Эшсез гражданнарга, шул исәптән пенсия алды яшендәге гражданнарга эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауда булышлык күрсәтү | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТИ ДУ | 2024 – 2025 еллар | хисап чорында теркәлгән эшсез гражданнарның гомуми санында үз эшен ачып җибәргән гражданнар өлеше, процент | | | | | 0 | кимендә 0,6 | кимендә 0,6 | ТР бюджеты | | | | | 0 | 63 662,0 | 63 662,0»; |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| (гражданнарга оештыру-консультация ярдәме күрсәтүне, индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп), шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

3.7.1 пунктчаның 17 графасында «543,5» саннарын «0» санына алмаштырырга;

3.7.2 пунктчаның 17 графасында «63 118,5» саннарын «0» санына алмаштырырга;

4.1.1 пунктчада:

3 графада «2019 – 2025 еллар» сүзләрен «2019 – 2020 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

9 графада «100» саннарын «0» санына алмаштырырга;

10 графада «100» саннарын «0» санына алмаштырырга;

11 графада «100» саннарын «0» санына алмаштырырга;

4.1.3.1 пунктчада:

3 графада «2022 ел» сүзләрен «2022 – 2023 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

9 графага «12» саннарын өстәргә;

4.1.4.1 пунктчада:

3 графада «2022 ел» сүзләрен «2022 – 2023 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

9 графага «12» саннарын өстәргә;

4.1.5 пунктчаның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.5. Эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү (башка җирлектә укуны кертеп) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру,Татарстан Республикасында яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында яраклы эш эзләү максаты белән теркәлгән гражданнарны, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән эшсез гражданнарны һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башларга теләгән эшсез пенсионерларның башка категорияләрен һәм Россия Федерациясе Президентының «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү дәүләт фондын төзү турында» 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән затларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

4.1.5.1 пунктчада:

1 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.5.1. Эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү (башка җирлектә укуны кертеп) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру,Татарстан Республикасында яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында яраклы эш эзләү максаты белән теркәлгән гражданнарны, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән эшсез гражданнарны һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башларга теләгән эшсез пенсионерларның башка категорияләрен һәм Россия Федерациясе Президентының «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү дәүләт фондын төзү турында» 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Указының 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән затларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

3 графада «2022 ел» сүзләрен «2022 – 2023 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

9 графага «12» саннарын өстәргә;

4.1.6 пунктчада:

3 графада «2019 – 2025 еллар» сүзләрен «2019 – 2022 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

9 графада «75» саннарын «0» санына алмаштырырга;

10 графада «75» саннарын «0» санына алмаштырырга;

11 графада «75» саннарын «0» санына алмаштырырга;

10.2.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «10.2.3. Оборона-сәнәгать комплексы предприятие- | | 2023 ел | оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре | | | | | 900 | | | ТР бюджеты | | | | | 536.2 | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ләре хезмәткәрләрен, шулай ук яраклы эш эзләүдә ярдәм сорап халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән һәм оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре белән укыту шартнамәсе төзегән гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) | | | хезмәткәрләре, шулай ук яраклы эш эзләүдә ярдәм сорап халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән һәм оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре белән укыту шартнамәсе төзегән гражданнар һөнәри укыту узды һәм өстәмә һөнәри белем алды, кеше | | | | | | | | РФ бюджеты | | | | | 53085,8». | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин